КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 27 февраль г.Казань № 138

Татарстан Республикасында кимерүчеләргә каршы көрәш һәм табигый-чыганак йогышлы авыруларны профилактикалау буенча кичектергесез чаралар турында

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 ел, 30 март, ФЗ-52 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2010 ел, 26 апрель, 38 нче карары белән расланган «Бөер синдромы белән геморрагияле бизгәкне профилактикалау» 3.1.7.2614-10 санитария-эпидемиология кагыйдәләре, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2010 ел, 31 май, 61 нче карары белән расланган «Туляремияне профилактикалау» СП 3.1.7.2642-10 санитария-эпидемиология кагыйдәләре, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2011 ел, 20 гыйнвар, 6 нчы карары белән расланган «Кешеләрдә лептоспироз инфекциясен профилактикалау» СП 3.1.7.2835-11 санитария-эпидемиология кагыйдәләре, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2014 ел, 22 сентябрь, 58 нче карары белән расланган «Санитарно-эпидемиологические требования к организации и проведению дератизационных мероприятий» СП 3.5.3.3223-14 санитария-эпидемиология кагыйдәләре нигезендә һәм халык арасында йогышлы авырулар таралуын кисәтү, Татарстан Республикасы территориясендә табигый чыганакларның активлыгын киметү, тычкансыман кимерүчеләр санын минималь дәрәҗәләргә төшерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

саламны, печәнне, кырлардан һәм урман массивларыннан чыгарып, тулы күләмдә пресслауны үткәрүне;

биогазлы технологияләр кулланып, терлекчелек калдыкларын юк итүнең нәтиҗәле системасын үстерү өчен кирәкле шартлар тудыруны;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларда тоташтан ике тапкыр дератизацияләү, ашлык складларында, элеваторларда, тегермәннәрдә, сугым пунктларында, икенчел чимал складларында ай саен дератизацияләү үткәрүне;

авыл хуҗалыгы эшләрендә мәшгуль затларны шәхси саклану чаралары белән.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

авыл хуҗалыгы предприятиеләре (терлекчелек, кошчылык һ.б.) объектларында дератизация чаралары үткәрүне;

авыл хуҗалыгы предприятиеләре объектларында ветеринария-санитария чаралары үткәрүне;

авыл хуҗалыгы предприятиеләре үткәрә торган дератизация чараларының нәтиҗәлелегенә дәүләт ветеринария күзәтчелеге оештыруны.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

медицина ярдәменә мөрәҗәгать иткән вакытта, эпидемиологик анамнез җыелмасына аеруча игътибар итеп, БСГБ клиник билгеләре булган авыруларны һәм авыруга шик булган затларны билгеләүне;

медицина оешмаларын БСГБ белән авыручыларны дәвалау өчен кирәкле дару препаратлары белән;

БСГБ авыруына шик булган барлык авыручыларга мәҗбүри лаборатория тикшерүен;

«Татарстан Республикасы буенча гигиена һәм эпидемиология үзәге (Татарстан)» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенә билгеләнгән тәртиптә кичектергесез хәбәр биреп, барлык БСГБ очракларын теркәүне һәм исәпкә алуны;

БСГБ авыруын профилактикалау буенча халык белән санитар-агарту эшен үткәрүне.

4. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

торак пунктлар (аеруча халык еш була торган), гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре, сәламәтләндерү оешмалары янәшәсендәге урман территорияләрен көнкүреш чүпләреннән, чыбык-чабыктан системалы рәвештә чистартуны үткәрүне;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе Территориаль органнарыннан алган чистартылырга тиешле урман территорияләре турында мәгълүматны эштә куллануны;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән берлектә барлык урманнан файдаланучыларның территорияләрне санитар чистарту буенча чараларны үтәүләрен тикшерүдә тотуны;

авыл хуҗалыгы эшләрендә мәшгуль затларны шәхси саклану чаралары белән;

авыл хуҗалыгы эшләрендә мәшгуль затлар арасында БСГБ профилактикасы буенча мәҗбүри инструктаж оештыруны.

5. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына чүпне сортларга аеру рәтләре төзү, каты көнкүреш калдыкларын полигоннарда күму күләмнәрен киметү исәбенә каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм эшкәртү системасын камилләштерү буенча эшне дәвам итәргә.

6. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына, гаепле затларны административ җаваплылыкка тартуны кертеп, көнкүреш калдыкларының санкцияләнмәгән чүплекләрен бетерүгә юнәлтелгән чаралар кабул итәргә.

7. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына халыкны БСГБ профилактикасы мәсьәләләре буенча мәгълүматлаштыруда булышлык күрсәтергә.

8. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

санитария-эпидемиягә каршы комиссияләр утырышларында тычкансыман кимерүчеләргә каршы көрәш һәм БСГБ профилактикасы чаралары буенча кичектергесез чаралар турында мәсьәләләрне карарга,

халыкның массакүләм ял урыннарында, йогышлы урыннарның табигый учакларында кимерүчеләрне юк итү буенча системалы рәвештә чаралар үткәрүне тәэмин итүне,

табигый-чыганак йогышларны профилактикалау һәм кимерүчеләргә каршы көрәш буенча территориаль (муниципаль) программалар эшләргә һәм кабул итәргә,

торак пунктлар янәшәсендәге урман территорияләрендә көнкүреш чүпләреннән, чыбык-чабыктан системалы рәвештә чистарту үткәрүне тәэмин итүне,

торак пунктларда иске корылмаларны, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, каты көнкүреш калдыклары полигоннарын санитария законнары таләпләренә туры китерү буенча чаралар кабул итәргә,

финанслар белән тәэмин ителеше Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетына аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты субвенцияләре исәбеннән гамәлгә ашырыла торган профилактик дератизация чараларын үткәрүне тәэмин итүне,

БСГБ табигый учакларында, урман массивлары һәм көнкүреш калдыклары полигоннары янындагы торак пунктларда тоташтан һәм киртәле дератизация эшкәртүләре үткәрүгә өстәмә финанс чаралары бүлеп бирүне һәм аларны максатчан куллануны күздә тотарга,

дератизация эшкәртүләре үткәрүгә муниципаль контрактлар төзегәндә, хезмәт күрсәтүчеләрнең махсус җиһазы, әзерлекле персоналы булуын, дератизация чараларын саклау һәм куллану шартларын саклауны исәпкә алырга,

гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре җитәкчеләре белән кишәрлекләрне яз һәм көз көне эшкәртү мәсьәләләре буенча, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе вәкилләрен чакырып, ел саен киңәшмәләр оештырырга һәм үткәрергә;

Татарстан Республикасы буенча «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт учреждениесе филиалына:

Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы предприятиеләре биләмәләрендә, объектларында тычкансыман кимерүчеләр барлыгына системалы рәвештә тикшерү үткәрергә,

авыл хуҗалыгы объектларында кимерүчеләргә каршы көрәш өчен кулланырга билгеләнгән тәртиптә рөхсәт ителгән кирәкле күләмдә родентицид чаралар сатып алырга һәм кулланырга;

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә:

биналарда, корылмаларда, кимерүчеләрнең үтеп керү һәм яшәү шартларын булдырмау максатында, санитария-техник чаралар үткәрергә,

оешмаларның территорияләрен һәм яндагы территорияләрне төзекләндерү;

биналарда һәм корылмаларда (шул исәптән махсус эпидемиологик әһәмияттәге объектларда, ай саен кабатлап) тычкансыман кимерүчеләргә каршы дератизацияләү чаралары оештырырга һәм үткәрергә,

балансta булган объектлар янындагы чистартылган территорияләрдә көз һәм яз көннәрендә тычкансыман кимерүчеләргә каршы профилактик дератизацияләү чаралары үткәрергә;

дезинсекцияләү һәм дератизацияләү буенча эшләр үткәрүне оештыручы һәм гамәлгә ашыручы дезинфекция профилендәге оешмалар җитәкчеләренә:

дератизацияләү чаралары нәтиҗәләренә җитештерү контролен оештырырга һәм үткәрергә,

аккредитацияләнгән белем бирү оешмалары базасында хезмәткәрләргә профессиональ белем бирү һәм квалификацияләрен күтәрү;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина академиясе» өстәмә профессиональ белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә:

дәвалау һәм медицина-профилактика профилендәге белгечләргә табигый-чыганак йогышларны профилактикалау буенча тематик укыту циклын оештырырга һәм үткәрергә,

дезинфекция профилендәге оешмалар белгечләренә дезинфекцияләү, дезинсекцияләү, дератизацияләү буенча, сораулар циклына мәҗбүри рәвештә дезинсекцияләү, дератизацияләү эшләре нәтиҗәләрен тикшерүдә тотуны, кимерүчеләр санын исәпкә алуны кертеп, тематик цикл оештырырга һәм үткәрергә;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә:

телевидение, радиотапшыруның республика, җирле каналларын, матбугат басмаларын кулланып, БСГБ авыруын профилакталау мәсьәләләре буенча халыкны мәгълүматлаштыру чараларын үткәрергә,

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән, зоогеография куркынычларын исәпкә алып, тоташтан һәм киртәле дератизация үткәрелергә

тиешле территорияләрне планлаштырырга, шул исәптән эшкәртүләр планына гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре янындагы урманга көзге киртәле дератизация үткәрүне кертергә,

Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган акчалар исәбеннән тоташтан һәм киртәле дератизация үткәрелергә тиешле территорияләр турында мәгълүматны мәнфәгатьле органнарга һәм оешмаларга (җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе һәм аның филиалларына) юлларга,

ачык территорияләрдә профилактик дератизация эшкәртүләрен үз вакытында оештыруга, үткәрүгә һәм аның сыйфатына контроль үткәрергә;

«Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенә:

алдавыч җимнәрне һәм кимерүчеләргә каршы башка көрәш чараларын халыкка сатуны оештырырга,

Татарстан Республикасы бюджеты субвенция чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган дератизация чараларының нәтиҗәлелегенә контроль үткәрергә,

«Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе составында дезинфекция профилендәге структур бүлекчәләр белгечләрен укытырга һәм аларның квалификацияләрен күтәрергә,

«Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе филиаллары тарафыннан БСГБ авыруын профилактикалау буенча халык арасында, белешмәлекләр һәм листовкалар таратып, киң санитария пропагандасы оештырырга.

9. «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына түбәндәгеләрне оештырырга тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы предприятиеләре объектлары җирләрен кимерүче тычканнарның торакка күченүенә системалы тикшерү үткәрү;

авыл хуҗалыгы объектларында план-системалы режимда дератизация үткәрү;

кимерүчеләргә каршы көрәш өчен авыл хуҗалыгы объектларында куллану өчен билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә рөхсәт ителгән родентицид чараларны сатып алу һәм куллану.

10. Татарстан Республикасы оешмалары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

оешма территориясен, участокларын һәм янәшә территорияне төзекләндерү;

кимерүчеләрнең үтеп керү һәм яшәү шартларын булдырмау максатларында бүлмәләрдә, биналарда, корылмаларда санитар-гигиена һәм инженер-техник чаралар үткәрү;

балансta тотучылары булып торган биналарда, бүлмәләрдә, корылмаларда һәм янәшә территорияләрдә кимерүчеләргә каршы дератизация чараларын оештыру һәм үткәрү;

яз һәм көз чистартылган территорияләрдә кимерүчеләргә каршы профилактик дератизация чаралары үткәрү.

11. Балансларында тычкан бизгәге, туляремия, лептоспироз табигый чыганаклары зонасында урнашкан җәйге сәламәтләндерү оешмалары булган оешма җитәкчеләренә ачыш алдыннан аларны түбәндәгеләр белән тәэмин итәргә тәкъдим итәргә:

тычкан кимерүчеләрнең санын һәм тычкан бизгәге белән зарарлануын билгеләү өчен җәйге сәламәтләндерү оешмасы территориясендә эпизоотологик тикшерү үткәрү;

җәйге сәламәтләндерү оешмасы тирәсендәге 500 метрлы радиуста урман массивларын чүп-чардан, ауган, коры-сары, куе агачлардан чистарту, күрсәтелгән территорияне урман паркларына китерү;

хуҗалык корылмаларының һәм торак биналарның кимерүчеләр керү мөмкинлеге;

җәйге сәламәтләндерү оешмасы территориясендә һәм корылмаларда тычкан төрендәге кимерүчеләрне юк итү буенча чаралар үткәрү;

агуланылган алдавыч җимнәр җәеп, 200 метрлы зонаның киртә дератизация оештыру;

урын-җир кирәк яракларны камера эшкәртүе аша үткәрү һәм бүлмәләрне юешләп дезинфекцияләү.

12. Дератизация буенча эшләрне башкаруны тәэмин итүче дезинфекцион профильдәге оешмалар җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

дератизация чараларының нәтиҗәлелегенә җитештерү контролен үткәрү;

аккредитацияләнгән белем бирү оешмалары базасында биш елга кимендә бер тапкыр хезмәткәрләрнең һөнәри укытуу һәм квалификацияләрен күтәрү.

13. Казан дәүләт медицина академиясе – «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» өстәмә һөнәри белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең Казан филиалына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә:

дәвалау һәм медицина-профилактика профиле белгечләре өчен табигый-чыганак инфекцияләрен профилактикалау буенча укытуның тематик циклын оештыру һәм уздыру;

дезинсекция, дератизация эшләре нәтиҗәләрен контрольдә тоту, кимерүчеләр санын исәпкә алу мәсьәләләре циклына мәҗбүри кертү белән дезинфекцион профиль оешмалары белгечләре өчен дезинфекция, дезинсекция, дератизация буенча тематик циклны оештыру һәм үткәрү.

14. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тоташ һәм киртә дератизацияләнергә тиешле территорияләрне планлаштыруны һәм үз вакытында төзәтмәләр кертүне үткәрергә, зоогеографик хәвефләрне исәпкә алып, шул исәптән эшкәртүләр планына гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек яки дача коммерциячел булмаган берләшмәләре янындагы урманга көзге барьер дератизация ясауны кертергә;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тоташ һәм киртә дератизацияләнергә тиешле территорияләр турында мәгълүматны кызыксынган органнарга һәм оешмаларга (җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы

Урман хуҗалыгы министрлыгы, участок урманчылыкларына, «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенә һәм аның филиалларына) җибәрергә;

ачык территорияләрне профилактик дератизация эшкәртүләрен вакытында оештыру, үткәрү һәм сыйфатын контрольдә тотарга;

авырулар билгеләре һәм профилактикалау чаралары турында җентекле мәгълүмат бирү белән, массакүләм мәгълүмат чараларын, листовкалар, плакатлар, бюллетеньнәр кулланып, табигый-чыганак авыруларын профилактикалау мәсьәләләре буенча халыкка гигиеник тәрбия бирүне уздырырга;

әлеге карар нигезендә үткәрелә торган чараларның нәтиҗәлелегенә анализ ясарга.

15. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, шулай ук Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсенә, «Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү институты» федераль бюджет фән учреждениесенә, «Татарстан Республикасында (Татарстан) Гигиена һәм эпидемиология үзәге» сәламәтлек саклау федераль бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасында халкының иммунитетына киеренкелек өчен серологик тикшеренүләрне ел саен уздыруны оештырырга тәкъдим итәргә.

16. «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» сәламәтлек саклау федераль бюджет учреждениесенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә:

хезмәт күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсе кысаларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган дератизация эшкәртүләренең нәтиҗәлелеген контрольдә тоту;

«Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесе составында дезинфекция профиленең структур бүлекчәләре белгечләрен биш елга кимендә бер тапкыр укыту һәм аларның квалификациясен күтәрү;

авырулар билгеләре һәм профилактика чаралары турында җентекле мәгълүмат бирү белән листовкалар, плакатлар, бюллетеньнәр кулланып, табигать-чыганак авыруларын профилактикалау мәсьәләләре буенча халыкка гигиеник тәрбия бирү.

17. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кимерүче-ләргә каршы көрәш һәм табигый-чыганак йогышлы авыруларны профилактикалау буенча кичектергесез чаралар турында» 2015 ел, 1 июнь, 392 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

18. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин